**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**13 декабрь, 2023 ел** **№ 367**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 206 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге территориясендә тәртипкә китерелгән һәм нәтиҗәле җирдән файдалану һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 206 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«1.1. кушымтада бирелгән Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре раслануга бәйле рәвештә, түбәндәге реестр номерлы территориаль зоналарны гамәлдән чыккан дип таныргa һәм аларга «архив» статусын бирергә:

-16:16-7.359 (Инженерлык инфраструктурасы зонасы (И2);

- 16:16-7.360 (Торак пункт территориясендә транспорт инфраструктурасы зонасы (И3);

-16:16-7.361 (Коммуналь хезмәт күрсәтү объектлары зонасы (КО);

-16:16-7.362 (Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле төзелеш зонасы (ОД1);

-16:16-7.363 (Рекреация һәм туризм объектлары зонасы (Р3);

-16:16-7.364 (Махсус билгеләнештәге зона (СН1);

-16:16-7.365 (Яшелчә бакчачылыгы зонасы (СХ3);

-16:16-7.366 (Авыл хуҗалыгы җитештерүе объектлары зонасы (СХ2)».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов